
# Иске Чаллы гомуми урта белем мәктәбе

1 нче сыйныфта әдәби уку фәненнән

**Сафина Р.З.**

**Тема**. Җәвад Тәрҗеманов «Тукран малае Шуктуган»



**Максат**: укучыларның уку һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү,
Җ.Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясе белән таныштыру;
дөрес, сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү; укучыларда кошларның тормышына кызыксыну хисләре, әдәплелек, тәрбиялелек сыйфатлары һәм кошларга карата игътибарлылык хисләре тәрбияләү.

# I. Оештыру өлеше.

Психологик уңай халәт тудыру.



## II. Актуальләштерү.

Г.Тукайның “Кошларга” шигырен сәнгатьле итеп уку.

– Кошларга ни өчен тияргә ярамый?

– Алар безгә һәм табигатькә нинди файда китерәләр?



## III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.

1. Кереш әңгәмә.

Дәрестә укылачак хикәянең исемен табышмак җавабын ачыклау.

Җәй шакылдый бу чүкеч,
Кыш шакылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч? (Тукран)

2. Балалар язучысы, шагыйрь һәм прозаик Җ. Тәрҗемановның тормыш юлы һәм иҗаты белән кыскача таныштыру.
3. Сүзлек өстендә эшләү.

Шалаш -
Табиб – хирург -
Агач кайрысы -
Ярканат -
Карыны ачкан -
Төсе китеп -
Кисмәннәр -

4. Хикәяне укытучының сәнгатьле укуы.
5. Хикәяне эчтән укырга кушу, сәнгатьле укырга әзерләнү.



## IV. Физкультминутка.

Әтәч канат кагынып
Кычкырды инде күптән.
Киерелдек – сузылдык та
Сикереп тордык иртән.
Урыннарны җыештырдык,
Кулларны, битне юдык.
Физзарядка ясарга дип,
Тышка йөгереп чыктык.
Җилкә өчен, куллар өчен
Ясадык күнегүләр.
Һәм саф һавада йөгердек,
Күтәрелде күңелләр.



**V. Яңа тема өстендә эшләү.**

1. Хикәяне чылбыр буенча укыту.
2. Хикәянең эчтәлеге өстендә эшләү.

- Хикәя сезгә ошадымы?
- Хикәядә сүз нәрсә турында бара?
- Тукраннар табигатькә нинди файда китерәләр?
- Шуктуган сезгә ошадымы? Ни өчен?

3. Кыскача эчтәлеген сөйләү.
4. Дәреслектәге сорауларга җавап бирү (76 бит).
5. Кошлар турында табышмакларга җавап табу.

Гөлдер – гөлдер киләдер,
Кызыл читек киядер. (Күгәрчен)

Тап – тап табагач,
Табагачта бер агач,
Койрыгы бер колач.(Саескан)


Урмый, чәчми,
Ил өстендә көн итә. (Чыпчык)

Урманнан чыгар, үзе чуар.
Ул нинди кош? (Боҗыр)

Кайсы кош кыш көне балаларын чыгара? (Чукыр)

Иң озын телле кошны атагыз. (Тукран)

Нинди кошны барабанчы кош диләр? (Тукран)



**VI. Йомгаклау.**

- Укучылар, тукраннар табигатькә нинди файда китерәләр?
- Кошларның файдасы турында нәрсәләр белдегез?

Әкиятнең дәвамын өегездә “Тукран малае – Шуктуган” исемле китаптан укып бетерегез.



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!